ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.05.2022 г. Заинск № 222

**«Ринат Фәрдиев исемендәге махсус премияне бирү турында» 2019 елның 07 маендагы 238 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Зәй муниципаль районының талантлы яшьләренә ярдәм итү, иң яхшы укучыларны бүләкләү, педагогик җәмәгатьчелекнең инновацион активлыгын стимуллаштыру максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Ринат Фәрдиев исемендәге елга бер мәртәбә бирелә торган махсус премия турында» нигезләмәне яңа редакциядә раслап, «Ринат Фәрдиев исемендәге махсус премияне бирү турында» 2019 елның 07 маендагы 238 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның “11” 05 222 номерлы карарына кушымта

**"Ринат Фәрдиев исемендәге елга бер мәртәбә бирелә торган махсус премия турында" нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Ринат Фәрдиев исемендәге махсус премия (алга таба – премия) Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениесенең иң яхшы укучысына бирелә.

1.2. Премия алуга кандидатны тәкъдим итү тәртибе әлеге нигезләмә белән билгеләнә.

1.3. Премия бер үк дәгъва итүчегә өч елга бер тапкыр гына бирелә.

1.4. Конкурсны уздыру һәм аның йомгаклары турында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында бастырыла.

## 2. Конкурс комиссиясенең составы һәм эш регламенты

2.1. Конкурс комиссиясе премия алуга кандидатларның тәкъдим ителгән документларына экспертиза әзерләү һәм үткәрүгә бәйле эшчәнлекне оештыру, мәгълүмати, документлар белән һәм хокукый яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

2.2. Конкурс комиссиясе составына:

Зәй муниципаль районы Башкарма комитетыннан;

- «ТР ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МК учреждениесеннән;

Зәй муниципаль районы мәгариф учреждениеләре директорлары советыннан;

- «Мәктәп укучыларының кече фәннәр академиясе» МБМ учреждениесеннән вәкилләр керә.

2.3. Конкурс комиссиясе рәисе булып Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, рәис урынбасары булып «ТР ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе " МКУ башлыгы тора.

2.4. Конкурс комиссиясе составы әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымтада күрсәтелгән.

2.5. Конкурс комиссиясе:

- агымдагы елның 15 маена кадәр конкурска тәкъдим ителгән материалларга техник экспертиза үткәрә;

- кандидатны сайлап ала һәм премиягә кандидатны тәкъдим итү турында карар кабул итә.

2.6. Конкурс әлеге нигезләмә белән билгеләнгән сайлап алу критерийлары нигезендә үткәрелә (2 нче кушымта);

2.7. Комиссия утырышын комиссия рәисе яисә аның кушуы буенча комиссия әгъзаларының берсе алып бара. Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия һәм "хуплыйм", "каршы", "тыелам" дип тавыш бирә ала. Конкурсның җиңүчесе - комиссия әгъзаларының күпчелеге тавыш биргән премиягә дәгъва итүче. Тавышлар тигез санда булганда, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

2.8. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм утырыштан соң 3 көннән дә соңга калмыйча комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

2.9. Комиссия карары катгый һәм ул яңадан каралырга тиеш түгел.

2.10. Конкурс җиңүчесе турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының Ринат Фәрдиев исемендәге махсус премиясен бирү турында карар кабул итү өчен җибәрелә.

## 3. Премиягә кандидатны күрсәтү тәртибе

3.1. Премия муниципаль, республика дәрәҗәсендә, Бөтенроссия фән олимпиадаларында һәм конкурсларда нәтиҗәле катнашкан, интеллектуаль, фәнни-тикшеренү һәм иҗтимагый эшчәнлектә ирешкән уңышлары өчен сәләтле балаларга социаль ярдәм күрсәтү максатларында бирелә.

3.2. Премиягә дәгъва кылучылар булып торалар:

- - гомуми белем бирү учреждениеләре тарафыннан тәкъдим ителүче укучылар (алга таба - кандидатлар);

- иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан тәкъдим ителүче гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары.

3.3. Конкурс комиссиясенә премия алу өчен (алга таба - конкурс комиссиясе) түбәндәге материалларны тәкъдим итәргә кирәк:

- конкурста катнашуга гариза (3 нче кушымта);

- агымдагы елның 5 маена кадәр премия бирелүгә кадәрге елның 6 маеннан алып узган чараларда катнашуның нәтиҗәләре буенча укучы эшчәнлеге нәтиҗәләрен раслый торган документлар;

- гомуми белем бирү учреждениесеннән кандидатка ирекле формада характеристика, өлгереш табеле.

Сайлап алуда катнашуга документларның тулы пакетын тапшырган кандидатлар кертелә. Премия алуга кандидатларның барлык материаллары агымдагы елның 5 маена кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрелә: 423520, Зәй шәһ., Крупская ур., 6 йорт, 99 нчы кабинет.

3.4. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ (алга таба - оештыручы) Ринат Фәрдиев исемендәге махсус премияне алуга кандидатларның тәкъдим ителгән документларына беренчел бәя бирүне оештыра.

3.5. Оештыручы:

- премия бирүгә кандидатлар документларын кабул итүне гамәлгә ашыра;

- тапшырылган документларга алдан экспертиза үткәрә;

- премия бирү буенча конкурс комиссиясе утырышын оештыру эшен башкара;

- премия бирүгә кандидатлар исемлеген формалаштыра;
- агымдагы елның 10 маена кадәр конкурс комиссиясенә премия алуга кандидатларның документларын тапшыра.

## 4. Премияне тапшыру тәртибе, аның саны һәм күләме

4.1. Премияне билгеләү ел саен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән башкарыла.

4.2. Премия җирле бюджеттан 30 000 сум (утыз мең) сум 00 тиен күләмендә бирелә.

4.3. Премия тантаналы шартларда тапшырыла.

Ринат Фәрдиев исемендәге елга
бер мәртәбә бирелә торган
махсус премия
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

**Зәй муниципаль районы башлыгы грантын бирү буенча конкурс комиссиясе составы**

| | | |
|---|---|---|
| Камалова Регина Николаевна | – | конкурс комиссиясе рәисе, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Сәфәргалиев Эрнст Рәис улы | – | конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, мәгариф идарәсе башлыгы |
| Әюпова Венера Мөхлисулла кызы | – | конкурс комиссиясе секретаре, мәгариф идарәсенең мәгълүмати һәм укыту-методик тәэмин итү бүлеге өлкән методисты |

**Конкурс комиссиясе әгъзалары:**

| | | |
|---|---|---|
| Ларина Альбина Равил кызы | – | мәгариф учреждениеләре директорлары советы рәисе, Зәй шәһәренең 4 нче урта мәктәбе директоры, 7 нче Төзелеш округы буенча Зәй шәһәр Советы депутаты |
| Шәрәфиева Гүзәл Мәхиян кызы | – | мәгариф идарәсе башлыгы урынбасары |
| Вәлиәхмәтова Миләүшә Камил кызы | – | мәгълүмати һәм укыту-методик тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| Вахитова Ирина Александровна | – | Зәй муниципаль районы мәгариф хезмәткәрләренең профсоюз оешмасы советы рәисе |
| Җиһаншина Гөлнара Мисхәт кызы | – | мәгариф идарәсенең план-икътисад бүлеге башлыгы |
| Гатина Лилия Даниял кызы | – | мәгариф идарәсенең мәгълүмати һәм укыту-методик тәэмин итү бүлеге методисты |

| | | |
|---|---|---|
| Сәфәрова Зарина Тоировна | – | методист МБУДО «ЦДООД-МАНШ» |
| Шәяхмәтова Лилия Фәнил кызы | – | «ЦДООД-МАНШ» МБУДО өстәмә белем бирү педагогы (килешү буенча) |
| Колесова Валентина Васильевна | – | 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы, «ЦДООД-МАНШ» МБУДО өстәмә белем бирү педагогы (килешү буенча) |

Ринат Фәрдиев исемендәге елга бер<br>мәртәбә бирелә торган махсус<br>премия турында нигезләмәгә<br>2 нче кушымта

**Конкурска тәкъдим ителгән эшләрне бәяләү критерийлары (балларда)**

| Ф.И.О. | Фәнни-тикшеренү эше нәтиҗәләре<br><br>Халыкара –20<br>Бөтенроссия – 15<br>Төбәкара - 13<br>Республика–10<br>Муниципаль- 5 | Предмет олимпиадалары нәтиҗәләре<br><br>Халыкара–35<br>Бөтенроссия– 30<br>Төбәкара- 15<br>Республика –10<br>Муниципаль- 5 | Кандидатның өстәмә белем бирү системасында катнашуы (түгәрәкләргә, секцияләргә, студияләргә йөрүе)<br><br>(0-10 балл) | Иҗади, интеллектуаль, спорт конкурсларында, фестивальләрдә, ярышларда уңышлары<br>Халыкара –20<br>Бөтенроссия – 15<br>Төбәкара- 13<br>Республика–10<br>Муниципаль - 5 | Социаль активлык мониторингы<br><br>Бөтенроссия – 16-20<br>Төбәкара – 11-15<br>Республика 6–10<br>Муниципаль– 0-5 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Ринат Фәрдиев исемендәге елга бер
мәртәбә бирелә торган махсус премия
турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Премия бирү буенча конкурс комиссиясенә**

Ринат Фәрдиев исемендәге елга бер мәртәбә бирелә торган махсус премиягә дәгъва итүче кандидат гаризасы

Катнашучының Ф.И.А________________________________________________
_____________________________________________________________________
Класс, мәгариф учреждениесенең тулы исеме ___________________________
_____________________________________________________________________

1. Фәнни-тикшеренү эшенең нәтиҗәләре

| Үткәрү датасы | Конференциянең/ семинарның һәм эшләрнең исеме | Казанышлар дәрәҗәсе |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

2. Фән олимпиадалары нәтиҗәләре

| Үткәрү датасы | Фән | Казанышлар дәрәҗәсе |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

3. Кандидатның өстәмә белем бирү системасында катнашуы (түгәрәкләргә, секцияләргә, студияләргә йөрүе)

| № п/п | Түгәрәкнең, секциянең, студиянең исеме | Кайчаннан шөгыльләнә |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

4. Иҗади, интеллектуаль, спорт бәйгеләрендә, фестивальләрдә, ярышларда ирешкән уңышлар

| Үткәрү датасы | Исеме | Казанышлар дәрәҗәсе |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

5. Социаль активлык мониторингы

| Дата | Социаль эшчәнлек өлкәсе | Эш төре<br>(күргәзмә әзерләү, сценарий язу, өмәдә катнашу һ. б.) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Тутыру датасы

Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенең имзасы

Гомуми белем бирү учреждениесенең мөһере